МУНИЦИПАЛЬНОЕ БЮДЖЕТНОЕ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ
«СРЕДНЯЯ ОБЩЕОБРАЗОВАТЕЛЬНАЯ ШКОЛА №20»
Г. АЛЬМЕТЬЕВСКА РТ

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Руководитель МО | Заместитель директора по УР | Директор школы |
| ______________ /Гараева А.М./ | ______________ /Николаева А.И./ | ______________ /Галанина С.Л./ |
| Протокол №1 от «28» августа 2025 г. | Протокол №1 от «29» августа 2025 г. | Приказ №201 от «1» сентября 2025 г. |

Аттестационный материал
для проведения промежуточной аттестации
по родному (татарскому) языку
для обучающихся 1-11 класссов
за 2025-2026 учебный год

«Принято»
Педагогическим советом
протокол № 1
от «29» августа 2025 года.

г. Альметьевск
2025 г.

## 1 сыйныф

### Май

Ямьле яз җитте. Җир өстен яшел үлән каплады. Агачлар яфрак ярды. Кошлар кайта башлады.

Малайлар күлдә балык тоталар. (18 сүз)

**Биремнәр.**

1. Икенче җөмләдә тартык аваз хәрефләрнең астына ике сызык сызарга.
2. Малайлар сүзен иҗекләргә бүлеп язарга.

## 2 сыйныф диктант

### Җәй көне.

Җәй көне без урманда ял итәбез. Ул урманда агачлар гөрләп үсә. Якын гына Ык елгасы ага.Тәмле – тәмле җиләкләр кызарып пешә. Анда хәйләкәр төлкеләр һәм куркак куяннар да яши. ( 28 сүз)

Биремнәр:

1.Күплек сандагы исемнәрнең астына бер сызык сызарга.

2.Тексттан сыйфатларны табып, күчереп язарга.

**3 сыйныф диктант**

**Көз җитте.**

Менә көз җитте. Агач яфраклары саргайды. Кошлар җылы якларга киттеләр.

Бер яңгырлы көндә Айдар бакчага бармады. Башта ул төрле кызык рәсемнәр карады. Аннан үзе карандашлар белән самолетлар, ракеталар ясады. Болар да туйдырды. Ул урамга чыкты. Айдар урамда кызык тапмады. Ул өйләренә кереп китте.

Биремнәр:

1.Беренче җөмләнең баш кисәкләрен билгеләргә.

2.Яңгылы сүзенә фонетик анализ ясарга.

**4 сыйныф диктант**

**Җәй көне.**

Матур җәй җитте. Зәңгәр күктә кояш елмая. Җылы җилләр исә башлады. Бөтен җирдә яз исе аңкый.Укучылар ясаган ояларда сыерчыклар сайрый. Алмагачлар яфрак ярды, чәчәк ата башлады. Болыннарда чуар күбәләкләр оча. Мәктәпләрдә укулар бетә. Җәйге ял башлана. ( 37 сүз)

Биремнәр:

1. Беренче җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен билгеләргә.
2. Җитте, елмая, аңкый, сайрый, оча, бетә, башлана фигыльләренең нинди заманда килүен билгеләгез.

**5 сыйныф(татар торкеме)**

**Әлеге өлештәге биремнәрне (А1-А5) үтәгәндә, дөрес дип табылган җавапны түгәрәк эченә алыгыз**

**А1** ь хәрефе **аеру билгесе** вазифасын башкарган очракны билгеләгез.
1) апрель
2) шөгыль
3) төньяк
4) ниһаять

**А2** Түбәндәге сүзләрнең кайсы **беренче** (беренче чәчәкләр) сүзенә синоним булып килә ала?
1) яңа
2) тәүге
3) алдынгы
4) иртәнге

**А3** **Яфраклардан** сүзенең мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленешен күрсәтегез
1) яф-рак-лардан
2) яфрак-лар-дан
3) яфрак-ла-р-дан
4) яф-рак-лар-да-н

**А4** Сыерчыклар сүзе ясалышы ягыннан нинди сүзгә керә?
1) кушма

2) кыскартылма
3) ясалма
4) тамыр

**A5** Түбәндәге сүзләрнең кайсы фразеологик әйтелмә?
1) мәш килү
2) туктаусыз сайрау
3) сагыз исе килү
4) көндезен җылыту

**2 нче өлеш**

**Текстны укыгыз һәм B1-B4;**

1) Кыш бетә, ә яз башлана. 2) Көндезге кояш кар ныгытмаларын вата. 3) Бөтен җирдә тамчы тамганы ишетелә.

4) Иртән өстә кояш балкый, аста кар ялтырый. 5) Өйләр янында чыпчыклар күңелле чыркылдый һәм күгәрченнәр гөрләшә. 6) Урманда тукраннар барабан кагалар. 7) Март аенда урман да җанлана. 8) Агач ботакларында бөреләр бүртә. 9) Каен, талларның ботаклары соргылт төскә керә.

10) Һәркайда сыерчыклар өчен оялар куела. 11) Карга, чәүкә, саесканнар күлләвектән су эчә.

**B1 – B2 биремнәренә җавапларны сүзләр белән языгыз.**

B1 4-6 нчы җөмләләр арасыннан антоним рәвешләрне парлап язып алыгыз.

B2 8-11 нче җөмләләрдән сүзләрне кушу юлы белән ясалган сүзне күчереп языгыз.

**B3 – B4 биремнәренә җавапларны цифр белән күрсәтегез.**

**B3** 1-3 нче җөмләләрдә ирен гармониясенә буйсынган ничә сүз бар?

**B4** 1-3 нче җөмләләрнең кайсында күчерелмә мәгънәле сүз бар?

**Эшне тулысынча бәяләү критерийлары:**

A1-A5 һәм B1-B4 нче биремнәрне тикшерү

Беренче һәм икенче бүлектәге һәр биремгә дөрес жавап биргән өчен укучыга берәр балл куела. Җавап ялгыш булса яки бөтенләй булмаса, О балл куела. Беренче бүлектәге 5 тест биременә дөрес жавап биргән өчен укучы жыярга мөмкин булган иң югары балл – 5, икенче бүлектәге кыска җавап бирүне таләп иткән В1-В2- биремгә дөрес җавап биргән укучы җыярга мөмкин булган иң югары балл – 4; ике биремгә В3-В4 – 4 балл

Беренчел балларны биш баллы шкала буенча билгегә күчерү түбәндәге таблица буенча тормышка ашырыла:

| **Билге** | **«2»** | **«3»** | **«4»** | **«5»** |
|---|---|---|---|---|
| Беренчел баллар | 0–6 (0-59%) | 7-9 (60-77%) | 10-11(78-89%) | 11-13(90-100%) |

| **Биремнәр** | **Җаваплар** |
|---|---|
| **А1** | **3** |
| **А2** | **2** |
| **А3** | **2** |
| **А4** | **4** |
| **А5** | **1** |
| **В1** | **Өстә-аста** |
| **В2** | **Һәркайда** |
| **В3** | **2** |
| **В4** | **2** |

**6 сыйныф тат теле**

1.Исемне тартым белән төрләндерегез һәм тәрҗемә итегез.

тәрәзә

2. Сүзләрне тәрҗемә итегез.

твоя тетрадь- их карандаши-
моя сестра- ваша книга-
наш урок- наш словарь-
его сумка- его шкаф-

3.Тиешле кушымчаларны куегыз.
Минем
дәфтәр... бар.

Синең
компьютер... бар.
Аның төсле карандаш... бар.

4.Бирелгән исемнәр белән җөмләләр төзегез.
әбием, укытучыбыз

5. Тартым белән төрләнгән исемнәрне кулланып сорау җөмләләр язгыз.

**2 вариант**

1. Исемне тартым белән төрләндерегез һәм тәрҗемә итегез.

урам

2. Сүзләрне тәрҗемә итегез.

наша тетрадь- твой словарь-
ваша сестра- моя книга-
их урок- наш карандаш-
его шкаф- его сумка-

3. Тиешле кушымчаларны куегыз.

Безнең китаб... бар.
Сезнең альбом .. бар.
Аларның плеер... бар.

4.Бирелгән исемнәр белән җөмләләр төзегез.
сумкаң, песиләре

5. Тартым белән төрләнгән исемнәрне кулланып сорау җөмләләр язгыз.

**КРИТЕРИИ ПРОВЕРКИ И ОЦЕНКИ ВЫПОЛНЕНИЯ ЗАДАНИЯ**
**по татарскому языку для учащихся 6 класса**

| № | Критерии оценивания ответа | Баллы |
|---|---|---|
| **1.** | Тәрәзәм- моё окно<br>Тәрәзәң- твоё окно<br>Тәрәзәсе- его окно<br>Тәрәзәбез- наше окно<br>Тәрәзәгез- ваше окно<br>Тәрәзәләре -их окно | 1 балл за каждый правильный ответ.<br>0 баллов за неправильный ответ или его отсутствие.<br>Всего **10 баллов** |
| **2** | Наша тетрадь- дәфтәребез<br>Ваша сестра- апагыз | 1 балл за каждый правильный ответ.<br>0 баллов за неправильный ответ или его отсутствие.<br>Всего **8 баллов** |
| **3.** | Безнең китабыбыз бар | 1 балл за каждый правильный ответ.<br>0 баллов за неправильный ответ или его отсутствие..<br>Максимум **3 балла** |
| **4.** | Синең сумкаң бик матур.<br>Безнең укытучыбыз безне походка алып бара. | 3 балла за каждый правильный ответ.<br>0 баллов за неправильный ответ или его отсутствие.<br>Минус 0,5 балла за каждую орфографическую ошибку.<br>Всего **6 баллов** |
| **5.** | Сезнең мәктәбегез зурмы?<br>Синең әниең кайда эшли? | 2 балла за каждый правильный ответ.<br>0 баллов за неправильный ответ или его отсутствие.<br>Минус 0,5 балла за каждую орфографическую ошибку.<br>Максимум **–неограниченное количество б** |

***Максимальное количество баллов* -более29**

| Оценка | Баллы | «2» | 16 |
|---|---|---|---|
| «5» | 26 и более | | |
| «4» | 21-25 | | |
| «3» | 17-20 | | |

## 7 нче сыйныф тат теле диктант

### Җәй.

Җәй! Исеменнән үк ниндидер бер рәхәтлек, яктылык, җылылык бөркелә аның. Җәй диюгә үк, хәтердә салават күперле җылы яңгырлар, чәчәкле болыннар, кайнар комлы елгалар яңара. Колакларга кошлар сайравы ишетелгәндәй була. Телләрдә җиләк, бал тәмнәре сизелә. Җәй иң күңелле, иң рәхәт фасыл дисәк, каршы килүче табылмас, шәт.

Җәй озын-озак яллар, каникуллар да әле ул. Хыялларның да канат җәйгән, илһамның да күңел кылларын чирткән вакыты. Шуңадыр инде, җәйне һәркем ел буе сагынып көтә. (71 сүз)

*(Й. Шәраповадан)*

Бирем:

1. Фигыльләрнең тамырыннан инфинитив ясап язарга:

   *1 нче вар.* ***Күр, сөйлә, чакыр.***

   *2 нче вар.* ***Көт, кит, йөр.***

2. 2 нче абзацтагы җөмләләрдәге сүзләрнең сүз төркемнәрен билгеләргә.

Бәяләү

1. Эш пөхтә башкарылса, 1нче һәм 2 нче грамматик бирем үтәлеп ,хатасы булмаган эшкә “5” куела.
2. Ике орфографик, ике пунктацион хаталы эшкә, 1 нче һәм 2 нче грамматик бирем үтәлсә, “4” куела.
3. 3 орфографик, 3 пунктуацион , 1нче һәм 2 нче грамматик бирем үтәлмәсә, бу эшкә “3 “ куела.
4. 4 орфографик хата, 4 пунктацион хаталы , грамматик биремнәре үтәлмәгән эшкә “2” куела.

**7 нче сыйныфның татар төркеме өчен татар әдәбиятыннан арадаш аттестация эше**

**Фәнис Яруллинның “Ак төнбоек” хикәясеннән өзекне укыгыз, биремнәрне үтәгез.**

Кечкенә чакта Гадилә белән Шөһрәт су коенырга бик яраталар иде. Әниләренең эшкә киткәннәрен генә көтеп торалар да, Каран буена йөгерәләр. Тәннәре җылынганчы яр башында утыралар да күлгә яңадан кереп китәләр. Күлдән төнбоек чәчәкләре җыялар.

Бервакыт Гадилә күп итеп төнбоек чәчәкләре җыярга уйлады. Шөһрәт аны күздән ычкындырмаска тырыша. Ак чәчәкләр, кызны үзенә чакыргандай, әкрен генә тирбәләләр. Ул һаман эчкә таба йөзә. Шөһрәт Гадиләнең бер батып, бер калкып маташканын күреп, күлгә ташлана. Ул килеп җиткәнче, кыз арудан һәм куркудан аңын югалткан һәм шактый гына күләмдә су йотып өлгергән була. Шөһрәт аны көч-хәл белән генә ярга алып чыга. Ләкин Гадиләдә җан әсәре булмый.

- Гадилә үлде, Гадилә үлде! – дип кычкыра-кычкыра, печәнчеләр янына чаба Шөһрәт. Колхозчылар килеп, Гадиләгә ясалма сулыш алдыралар. Озак, бик озак азапланганнан соң гына кызга җан керә. Аны атка салып алып китәләр.

Берничә көннән инде тәмам терелеп өлгергән Гадилә Шөһрәтләргә килеп керде. Шөһрәт, Гадиләнең батуында үзен гаепле санаганлыктан, курка-курка гына кыз артыннан иярде. Ләкин аның куркуы юкка икән.

– Кызны үлемнән коткаргансың бит. Маладис икәнсең. Герой дими сине кем дисең инде. Шуның өчен үзеңә костюм-чалбар алдым әле. Менә дигән егетләрские, - диде Гадиләнең әтисе.

Шөһрәт Илгиз абыйсының алмый булдыра алмады. Гадиләне судан тартып чыгаруны зур батырлыкка санап, чын күңелдән рәхмәт әйтүләре һәм кыйммәтле костюм бүләк итүләре Шөһрәтне нык дулкынландырды. Авыл корреспонденты Рәмил зур мәкалә язып чыкты. Газетаның битләрендә аның «Суга батучыны коткарган өчен» медале белән бүләкләнүе турында указ да бар иде. Бу кинәт килгән дан малайны әллә нишләтеп җибәрде. Үзе дә аңламастан эшләп ташлаган батырлыгы аны башка балалардан аерды.

Шөһрәт үсте. Газета битләре саргайды. Газета битендәге сүзләр җуелса да, Шөһрәт күңелендә ул һаман сакланды. Гадиләне ул үзенә бурычлы дип саный башлады. Шул хакта кызның исенә төшергәләүдән дә тартынмады. Бервакыт ул ничәнчедәр класста укыганда:

– Гадилә, өйгә эшләрне эшләдеңме? – дип килеп керде.

– Эшләдем.

– Кая алайса миңа дәфтәреңне бир. Тиз генә күчереп куйыйм.

– Ничек инде сиңа дәфтәр бирим? Аңламасаң сора, аңлатырмын. Ә кешедән күчерү гаделсезлек бит.

– Синең аңлатканнарыңны тыңлап торырга вакытым юк. Малайлар белән тауга менәбез.

– Алайса, кайткач килерсең.

– Икешәр тапкыр килергә үзеңне кем дип белдең? – дип кызып китте Шөһрәт. Ул бу минутта үзен кимсетелгән, кыерсытылган итеп тойды. – Әле килгәнемә рәхмәт әйт. Үзеңнең миңа бурычлы икәнеңне онытма.

Гадиләнең өстенә утлы кисәү ыргыттыйлармыни? Кызу булып китте. Шөһрәт авызыннан мондый сүзләр элек тә ишеткәләсә дә, һаман үзенең дөньяда яшәве белән кешегә бурычлы икәненә күнегеп җитә алмый иде ул. Ул үзе кемгә дә булса яхшылык итсә, шуны кешенең исенә төшерергә чын-чынлап ояла.

– Мә, оялмасаң күчер, – дип, дәфтәрен атты ул Шөһрәткә.

– Оялырга, мин кеше әйберен урламаган, – диде Шөһрәт.

Караклыкның башы энә урлаудан башлана диләр. Ялкаулыкның да башы менә шулай кеше хезмәтеннән файдаланудандыр, мөгаен. Шөһрәт баштарак вакыты җитмәгәндә яки үзе аңламаганда гына Гадиләдән күчергәләсә, тора-бара бу аның гадәтенә кереп китте. Кыз да гел-гел каршылык күрсәтмәде, чөнки теге сүзләрне ишетүдән курыкты. Хәзер Шөһрәтнең бөтен эшен Гадилә эшли иде. Шөһрәт аның бурычлы булуын гел кисәтеп торды һәм Гадилә аның өчен барысына да әзер дип сөйләде. Менә беркөн бөтен сыйныф алдында:

– Гадилә,  бөтен класска ишетелерлек итеп «мин синең кәләшең» дип әйт әле. Моңа ышанып җитмәүчеләр бар икән, - диде.

Гадилә үзе белән шаяралар дип уйлап, урынына барып утырмакчы булды, ләкин Шөһрәт аның юлына аркылы төште:

– Давай әйт. Син бит миңа гомереӊ белән бурычлы... Кыз кинәт агарынып китте. Елмаерга торган иреннәре усал кысылды. Ул Шөһрәтнең мыскыллаудан чалшаебрак торган йөзенә чалтыратып чабып җибәрде. Класста, әйтерсең бомба шартлаттылар, гөрс итте дә тынды. Гадилә сумкасын да алмыйча, урамга чыгып йөгерде.

Берничә көн Гадилә дә, Шөһрәт тә мәктәпкә килмәделәр. Бераздан классташ дуслары Гадиләнең район мәктәбендә укый башлавын ишеттеләр. Ә Шөһрәт ярты ел каңгырып йөргәннән соң, кайсыдыр шәһәргә һөнәр училищесына китеп барды. Ике дусның язмышлары шулай аерылды.

**Биремнәр.**

**<u>1.Текстның эчтәлегенә туры килгән җөмләгә “+”, туры килмәгән җөмләгә “-” билгеләре куегыз.</u>**

1)Күлдә кыңгырау чәчәкләре бик күп._____

2)Гадилә бата башлады._____

3)Шөһрәт Гадиләне судан тартып чыгарды._____
4)Гадилә торып утырды._____
5)Кыз Шөһрәтне үлемнән коткарды._____
6)Гадиләнең әтисе Шөһрәткә велосипед бүләк итте._____
7)Шөһрәт Гадиләдән өй эшләрен күчерә башлады._____
8)Малай Гадиләнең чәчен тартып уйнады._____
9)Шөһрәт малайларга үзенең өстенлеген күрсәтергә тели._____
10)Дуслар аерылыштылар._____

**2. Сорауларга кыска җавап языгыз.**
а) Шөһрәт Гадиләне ничек коткара?
ә) Шөһрәткә ничек рәхмәт әйтәләр?
б) Гадилә нинди кыз?
в) Ике дусның язмышы ничек тәмамлана?

**3. Хикәя жанрына бәяләмә бирегез.**

**4. Хикәянең төп фикере нинди?**

**5. Шөһрәт турында фикерләрегезне языгыз. Аңа характеристика бирегез.**

**6. Шөһрәткә киңәшләр бирегез.**

**7. Мәкальләрне дәвам итеп языгыз.**
а) Йөз сум акчаң булганчы, ... .
ә) Дуслык авыр вакытта ... .
б) Дусны табу җиңел, ... .

**8. Мәкальләрдән файдаланып, "Дуслык акчага сатылмый" дигән темага 45 сүздән ким булмаган хикәя төзеп языгыз.**

**8 сыйныф тат теле**
**Контроль диктант "Дуслык".**
Дуслыкның гүзәл хис икәнен аңлау өчен, философ булу кирәкми дә. Ышаныч, түземлелек, уртак сөенеч, күпмедер дәрәҗәдәкөнләшү хисе — дуслыкка бар да сыя.
Дуслар серләрен яшерми. Балачактан без иң якын кешебезне дус-сердәш дип саныйбыз. Башкаларгакирәк тәбулмаган нәрсәне арадаолыбер сер итепсаклаганбулабыз. Улаерымгынакиногакитсә дә, үпкәлибез. Әммаболар бар да вакытлычагына бит. Елларүтәр, карашларүзгәрер. Дусларыбызартыр.

Кем беләндерәдәбият-сәнгатьтурындагәпләшербез, кем беләндеряңа әйберәлгандакиңәшербез, кемнәндеркыенчакта ярдам сорарбыз.
Чын дуслык — гомерлек. Шөгыльләребез яңара, танышларыбыз алышына, үзебез дә үзгәрәбез. Яңа дуслар да табыла. Юк, иске дуслар онытылмый. Бары тик вакытлар үтү белән аралар ерагаерга, фикерләр туры килмәскә мөмкин. Якын дус та мәңгелек түгел — моның белән килешергә туры килә. *(118 сүз.)*(Матбугат битләреннән)
**Бирем.** Тиндәш кисәкләрнетабып, асларынасызарга.

**9 нчы сыйныф диктант**

Канатлы хыял

Айтуганның ерактагы дәү әниләренә кунакка барганы юк иде әле. Бүген әнисе ике билет алып кайткан. Иртәгә юлга чыгачаклар.

**Бу хәбәрне ишеткәч, сөенеп бетә алмады малай.** Ничек инде шатланмыйсың ди? Ике бәхет берьюлы килде ич! Дәү әнисен күрмәгәнгә елдан артты инде. Сагынды Айтуган дәү әнисен. Димәк иртәгә күрәчәк ул аны. Алар самолетта очачаклар. Самолетка утыру да малайның күптәнге хыялы иде. Район үзәгеннән шәһәргә кечкенә самолет оча очуын…

Икенче көннең житүен түземсезләнеп көтеп алды Айтуган. Урыннары да алгы рәттә, очучылар кабинасы янына туры килгәч, тагын да куанды.

Пассажирлар утырып бетүгә, самолет гүләп эшли дә башлады. Очып китәргә хәл җыйгандай, бер урында талпынып торды да йөгереп китеп тә барды. Озак та үтмәде, самолет, кояш яктысында ялтырап, югарыга, биеккә юл алды . (107 сүз)

Бирем:

Билгеләнгән иярченле кушма җөмләне мәгънә һәм төзелеш ягыннан тикшерү.

**10 нчы сыйныф диктант**
Алиш белән очрашулар.

Тагын бераздан безнең түгәрәккә Язучылар берлегеннән ярдәмгә даими шеф та билгеләделәр. Бу кеше Абдулла Алиш иде. Бу вакытта мин, зурдан кубып, завод уйлап табучылары турында повесть язарга керештем. Алиш катнашкан утырышларның берсендә бу әсәремнән бер өзек укыдым. Хәзер аңлыйм: әлбәттә, ифрат шәфкатьле шефыбыз бу эшне мине дәртләндерү өчен эшләгәндер. Әмма шунысы хак: ул мине үтереп мактады. “Мин бу иптәш әсәрен укыганда ук кул чапмакчы идем, тик аны бүлдерәсем килмәде”,- диде. Аның шул сүзләреннән соң минем күңелем күкнең җиденче катына очты, һәм мин һәр буш вакытымны повестька багышладым.
Абдулла Алишның кара хәтфәдәй күзләре, тыныч йөз-кыяфәте, икегә ачып таралган чәчләре – барысы да бүгенгедәй күз алдында. Урта буйлы, нык бәдәнле, матур кеше иде. Беркайчан да чыгарыннан чыкмас, һәрнәрсәне тулы һәм ачык итеп аңлатыр. Мин аның үзенчәлекле яңгыравык тавышын да ачык хәтерлим. (128 с.)

Бирем. (1)Тексттан иярченле ушма җөмләләрне табарга, (2) җөмлә чикләрен билгеләргә.

**11 сыйныф диктант**

Ил хәтере

Хәтер - кешенең намусын, вөжданын үлчәү бизмәне. Ата-баба хәтере - ил хәтере, дигәннәр борынгылар. Бары тик хәтере нык кеше генә җирдә нык тора. Хәтер - бөек көч ул. Һәрбер халык, һәрбер милләт үткәне белән көчле. Үткәне - аның тирән киткән тамырлары. Үткәне оныткан милләт яшәүгә ышаныч югалта.

Хәтере нык халыклар җиңелүне белмәгәннәр, бернинди көч алдында да тез чүкмәгәннәр. Кайчандыр үзләрен бөек халыкка, җиңелүне белмәс дәүләткә санаган баскынчыларның хәзер гасыр төплегендә, тарих битләрендә исемнәре дә калмаган. Теге яки бу

халыкның бәйсезлегенә, азатлыгына, үткәненә кизәнгән һәрбер милләт - олымы ул, кечеме - барыбер тарих тарафыннан кайчан да бер үз җәзасын алачак. Бу турыда бер генә минутка да онытырга ярамый. Һәрбер адәм баласы, нинди генә милләттән булмасын, үзенең үткәнен истә тотарга, бөек үткәненә таянып горурланырга тиеш. (119 сүз) (М. Хәсәнов)

Бирем

Соңгы җөмләгә синтаксик анализ ясарга.